**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ПӘНӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# К А Р А Р

**№ 142** **29 июль 2024 ел.**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы 2016 елның 22 апрелендәге 28 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәләрне» раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, Федераль хезмәт вазыйфасын биләүче затларның һәм башка затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында» 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указы нигезендә, Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы 2016 елның 22 апрелендәге 28 номерлы карарына Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлегендә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында муниципаль вазыйфаларны хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 4 нче пунктта «, Башкарма комитет җитәкчесе» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 6 нчы пунктта «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә (алга таба - Комиссия)»

сүзләрен «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү комиссиясенә (алга таба - Комиссия)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 8 нче пунктта «2014 елның 14 ноябрендәге 418 номерлы ««Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе» турындагы нигезләмәне раслау хакында» сүзләрен « 2018 елның 6 нчы июльдәге 298 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе» турында нигезләмә хакында» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 1 нче номерлы кушымтада «Зәй муниципаль берәмлеге Югары Пәнәче авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу Комиссиясе утырышында» нигезләмәсендәге сүзләрне «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү Комиссиясе утырышында» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2 нче номерлы кушымтада «Зәй муниципаль берәмлеге Югары Пәнәче авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу Комиссиясе утырышында» нигезләмәсендәге сүзләрне «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү Комиссиясе утырышында» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 3 нче номерлы кушымтада «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу Комиссиясе утырышында» нигезләмәсендәге сүзләрне «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.
3. Карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Югары Пәнәче авыл җирлеге**
**Советының Рәисе** **М. Х. Туктаров**